Татарстан Республикасы Кукмара
Түбән Үрәс җирлеге Советы
КАРАР

17.02.2025 №12

**Кукмара муниципаль районы Урәсбаш авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында «Кукмара муниципаль районы Урәсбаш авыл җирлегенең Түбән Үрәс торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Урәсбаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елның 07 февралендә 18 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә. «Кукмара муниципаль районы Урәсбаш авыл җирлегенең Түбән Үрәс торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Урәсбаш авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Урәсбаш авылы, Пионерская ур., 21 адресында урнашкан мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Урәсбаш авыл җирлегенең Түбән Үрәс торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 25 ноябрендәге 2 номерлы Урәсбаш авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

- беренче абзацта «2000 сум» сүзләрен «600 сум» сүзләренә алмаштырырга.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы В.Г. Сәфәров